СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 303

2022 елның 15 декабрендәге 230 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2022 елның 31 декабрендәге«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 109-ТРЗ номерлы, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 1-ТРЗ номерлы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 15 декабрендәге 230 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1.пунктта «Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәләренә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе күрсәтмәләренә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.9.1 пунктының 7.4 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**